| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2024 п.г.т.Алексеевское № 49

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондыннан торак урыннарын арендалау шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бердәм торак комиссиясен төзү турында» 21.12.2018 ел, № 470 карары нигезендә,

**карар бирәм:**

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь кыйммәте күләмен билгеләргә (Кушымта):

1.1. гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе тәшкил итә:

1.1. ялгыз яшәүче граждан әчен -612 252 сум.;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен -1 224 504 сум.;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен -1 836 756 сум.;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен -2 449 008 сум.;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен- 3 061 260 сум.;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен -3 673 512 сум.;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен- 4 285 762 сум.;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен- 23 850 сум.;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен -23 850 сум.;

1.2.3. өч кешедән торган яки артык булган гаилә өчен-23 850 сум.;

2. Бердәм торак Комиссиясе әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларына таянып, гаиләнең һәр әгъзасының яисә ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә, аларны торак фондының социаль файдаланудагы торак урыннарын наем шартнамәләре буенча бирүгә мохтаҗ дип тану максатында эш итәргә тиеш.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.02.2024 № 49
карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү исәбе**

1. СЖ = НП х РС х РПС, монда
СЖ- базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече яки милек бәясе чиге;
НП -гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС- гаилә әгъзалары саны;
РПС -торак бинаның бер квадрат метр мәйданынын уртача исәпләнгән базар бәясе - 34 014 сум. «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган сешмасынын 23.01.2024 елның 10 номерлы хатының уртача бәясе кулланылды.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 34 014 х 18 х 1 = 612252 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 2 = 1224504 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 3 = 1836756 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 4 = 2449008 сум
д) биш кешелек гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 5 = 3061260 сум
е) алты кешелек гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 6 = 3673512 сум
ж) җиде кешелек гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 7 = 4285762 сум

2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе СЖ ның исәп-хисап күрсәткеченә тиң дип кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең максималь күләме билгеләнә:

1) торак урыны сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә, гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем дәрәҗәсеннән чыгып, агымдагы шартларда банктан ипотека кредиты алу өчен, торак урыны сатып алу өчен, СЖның исәп-хисап бәясе буенча, формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС)-$^{КП}$) / (0,25 х РС), монда:

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ- исәпләнгән күрсәткеч;

ПС -айлык кредит буенча процент ставкасы (Россия Банкы мәгълүматлары буенча еллык ипотека буенча уртача ставка 16% яки айга 16/100/12, башлангыч взнос шарты белән 30%);

КП - «Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматлары буенча кредитның бөтен срогы (айлар саны) өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны кредит бирү срогы 20 ел яки 240 ай;

РС- гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25- кредит буенча түләү нисбәте гаиләнең айлык кереме белән;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 x 612252 x (16/100/12)/ (1- (1 + (16/100/12))-240) /(0,25 x 1) = 23850 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 x 1224504 x (16/100/12)/ (1-(1 + (16/100/12))-240) /(0,25 x 2)= 23850 сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә;

ПД = 0,7 x 1836756 x (16/100/12)/ (1-(1 + (16/100/12))-240) /(0,25 x 3)= 25850 сум